КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 30 декабрь г.Казань № 1265

Татарстан Республикасы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләүне һәм уздыруны оештыру турында

«Бөтенроссия авыл хуҗалыгы санын алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 108-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны оештыру турында» 2020 елның 29 августындагы 1315 номерлы карары нигезендә һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм уздыру буенча үзара хезмәттәшлеген оештыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм уздыру буенча ведомствоара комиссия төзергә.

2. Кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм уздыру буенча ведомствоара комиссия һәм аның составы турында нигезләмәне расларга.

3. Татарстан Республикасы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны (алга таба - авыл хуҗалыгы микросанын алу) әзерләүгә һәм уздыруга бәйле мәсьәләләр буенча федераль башкарма хакимияте органнарының территориаль органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлеккә вәкаләтле итеп Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгын билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына комиссия рәисе вазыйфаларын йөкләп, муниципаль берәмлекләрдә авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм уздыру комиссияләрен төзергә;

тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә яшәүче җирдән файдаланучылар турында белешмәләрне, аларга беркетелгән, 2021 елның 1 гыйнварына актуаль булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алу белешмәләре нигезендә, җир мәйданы һәм терлекләрнең баш санын күрсәтеп, билгеләнгән срокларда Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органына тапшыруны тәэмин итәргә;

Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органына тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарын авыл хуҗалыгы микросанын алу объектлары турында белешмәләр җыюга җәлеп итүдә, шулай ук авыл хуҗалыгы микросанын алу объектлары турында белешмәләр җыюны гамәлгә ашыручы затларны укыту һәм аларның эше өчен яраклы урыннар сайлауга, авыл хуҗалыгы микросанын алу кәгазьләрен һәм башка документларны саклау ярдәм итәргә;

2021 елда административ-территориаль һәм муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кормаска, шулай ук географик объектларның исемнәрен үзгәртмәскә.

5. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирү оешмалары мөгаллимнәрен һәм студентларын авыл хуҗалыгы микросанын алу объеклары турында мәгълүмат җыючы затлар сыйфатында җәлеп итүдә ярдәм итәргә.

6. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча агентлыгына авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләүне һәм уздыруны мәгълүмати яктырту, авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм уздыру мәсьәләләре буенча мәгълүмати-аңлату эшләрен гамәлгә ашырырга.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры М.А.Җәббаровка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 30 декабрь, 1265 нче
карары белән расланды

## Татарстан Республикасы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм уздыру буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмә

### I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм уздыру буенча ведомствоара комиссия (алга таба - ведомствоара комиссия, авыл хуҗалыгы микросанын алу) «Бөтенроссия авыл хуҗалыгы санын алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 108-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны оештыру турында» 2020 елның 29 августындагы 1315 номерлы карары нигезендә Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органына, шулай ук федераль башкарма хакимият органнарының башка территориаль органнарына Татарстан Республикасы территориясендә авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм уздыру буенча үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда булышлык күрсәтү максатларында оештырылган.

1.2. Ведомствоара комиссия федераль башкарма хакимият органнарының, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарының (алга таба - җирле үзидарә органнары) авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм уздыру буенча үзара эшчәнлеген оештыру өчен төзелгән коллегиаль орган булып тора.

1.3. Ведомствоара комиссия үз эшендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль конституциячел законнар, федераль законнар, Россия Федерациясе Президентының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, шулай ук әлеге Нигезләмә белән җитәкчелек итә.

### II. Ведомствоара комиссия бурычлары

2.1. Ведомствоара комиссиянең төп бурычлары булып торалар:

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарының, җирле үзидарә органнарының авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм уздыру буенча килешенгән гамәлләрен (үзара хезмәттәшлеген) тәэмин итү;

авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләүгә һәм уздыруга бәйле мәсьәләләрне оператив хәл итү;

Татарстан Республикасы халкы арасында авыл хуҗалыгы микросанын алуны уздыру турында мәгълүмат-аңлату эшләрен башкару.

2.2. Ведомствоара комиссия үзенә йөкләнгән бурычларны гамәлгә ашыру өчен түбәндәге мәсьәләләрне карый:

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарының, җирле үзидарә органнарының авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү, уздыру барышы турында, аның материалларын эшкәртү һәм авыл хуҗалыгы микросанын алу йомгакларын рәсми бастырып чыгару турында үзара хезмәттәшлеге;

авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм уздыру;

авыл хуҗалыгы микросанын алуны уздыру эшенә төрле оештыру-хокукый рәвешләрендәге оешмаларны җәлеп итү.

## III. Ведомствоара комиссиянең хокуклары

3.1. Ведомствоара комиссия төп бурычларны гамәлгә ашыру өчен түбәндәгеләргә хокуклы:

үз утырышларында авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм уздыру барышы турында Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары вәкилләрен тыңларга;

билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарыннан, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм уздыру мәсьәләләре буенча кирәкле материаллар соратып алырга;

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, җирле үзидарә органнарына авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм уздыру мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр җибәрергә;

ведомствоара комиссия эшенә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары вәкилләрен, фәнни һәм иҗтимагый оешмалар вәкилләрен, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларын җәлеп итәргә.

## IV. Ведомствоара комиссия составы

4.1. 6. Ведомствоар комиссия составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

4.2. Ведомствоара комиссия рәис, аның урынбасары, ведомствоара комиссия әгъзаларыннан һәм секретарьдан тора.

4.3. Ведомствоара комиссия составына федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, оештыру-хокукый рәвешенә бәйсез рәвештә оешмалар, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре керә.

## V. Ведомствоара комиссиянең эш тәртибе

5.1. Ведомствоара комиссия эшчәнлеген рәис җитәкли. Ведомствоара комиссия

рәисе булмаган очракта, аның функцияләрен ведомствоара комиссия рәисе урынбасары башкара.

5.2. Эшче төркем утырышлары кирәк булуга карап, әмма кварталга кимендә бер тапкыр үткәрелә. Ведомствоара комиссия утырышларын тиешле чыганакларга язып аудио- һәм видеоконференцияләр режимында уздырырга мөмкин.

5.3. Ведомствоара комиссия рәисе (ул булмаганда урынбасары) мәсьәләләрне карау тәртибен билгели, ведомствоара комиссия утырышларының көн тәртибен раслый, ведомствоара комиссия составын үзгәртү турында тәкъдимнәр кертә.

5.4. Ведомствоара комиссия утырышларының көн тәртибе авыл хуҗалыгы микросанын алуны уздыру эшләре планы нигезендә Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенеж Татарстан Республикасы буенча территориаль органы тәкъдимнәре нигезендә төзелә.

5.5. Ведомствоара комиссия әгъзалары ведомствоара комиссия утырышларында шәхсән үзләре катнаша һәм ведомствоара комиссия утырышында карала торган мәсьәләләр турында фикер алышканда тигез хокукларга ия.

5.6. Ведомствоара комиссия утырышы, әгәр анда әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, хокуклы дип санала.

5.7. Ведомствоара комиссия карарлары утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, рәис тавышы хәлиткеч булып тора (ул булмаганда урынбасарныкы).

5.8. Ведомствоара комиссия утырышында кабул ителә торган карарлар ведомствоара комиссия утырышының беркетмәләре рәвешендә рәсмиләштерелә. Карарларга ведомствоара комиссия рәисе (ул булмаганда, аның утырышта рәислек итүче урынбасары) имза сала.

5.9. Ведомствоара комиссия эшен оештыру-техник тәэмин итү Федераль дәүләт статистика хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

---

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 30 декабрь, 1265 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм уздыру буенча ведомствоара комиссия составы

| | |
|---|---|
| Җәббаров Марат Азат улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры |
| Гатауллина Наталья Вячеславовна | Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы җитәкчесе, комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Гайнетдинов Сажидә Мөхәммәт кызы | Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы җитәкчесе урынбасары, комиссия секретаре (килешү буенча) |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Байтимеров Камияр Миҗаһит улы | Татарстан Республикасы Фермерлар, крестьян хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары ассоциациясе президенты (килешү буенча) |
| Вәлиев Айрат Рәсим улы | «Казан дәүләт энергетика университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Гәрәев Раил Рүзәл улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Башкарма хакимият органнарының үзара хезмәттәшлеген координацияләү идарәсе башлыгы |
| Гарипов Илнур Мәхмүт улы | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары –Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Гобәйдуллин Әгъзам Самат улы | «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Дейнекин Владимир Федорович | Татарстан Бакчачылар берлеге идарәсе рәисе (килешү буенча) |
| Долгов Марат Шамил улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы урынбасары |
| Костин Артем Петрович | Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Мостафина Әлфинур Әхәт кызы | Федераль дәүләт статистика хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органының авыл хуҗалыгы һәм әйләнә-тирә мохит статистикасы бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Мөхәммәтҗанов Фәргать Госман улы | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының җәмәгать тәртибен саклау буенча полиция башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Равилов Рөстәм Хәмит улы | «Н.Э.Бауман ис. Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе» федераль дәүләт бюджет югары белем мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Сәлимгәрәев Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе (килешү буенча) |
| Фаттерахманов Ленар Рифат улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм кулланучылар базары идарәсе башлыгы |
| Хиалеев Эдуард Данил улы | Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Якушев Сергей Леонидович | штаб башлыгы - Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы урынбасары (килешү буенча). |

---